**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

ПРИКАЗ

04.10.2016 г. Казань № 086.1-ОД

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан архив эше өлкәсендә түләүле хезмәт күрсәтүләр тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан архив эше өлкәсендә түләүле хезмәт күрсәтүләр процедурасын, шул исәптән түләүле хезмәт күрсәтүләр вакытында бәяләр барлыкка килү тәртибен һәм шартларын тәртипкә салу максатларында, б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан архив эше өлкәсендә түләүле хезмәт күрсәтүләр тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре учреждениеләр тарафыннан архив эше өлкәсендә күрсәтелүче түләүле хезмәтләр исемлеген билгеләү буенча норматив хокукый документлар, шулай ук һәр хезмәт күрсәтүнең тәртибен, шул исәптән расланган Түләүле хезмәт күрсәтүләр тәртибе һәм шартлары нигезендә хезмәт күрсәтү өчен түләү күләмен билгеләү буенча норматив хокукый документлар кабул итәргә тиеш.

3. Җирле үзидарә органнарына муниципаль учреждениеләр тарафыннан архив эше өлкәсендә түләүле хезмәт күрсәтүләр һәм алар өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча
дәүләт комитетының
04.10.2016 г. № 086.1- од
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан
архив эше өлкәсендә түләүле хезмәт күрсәтүләр
тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан архив эше өлкәсендә түләүле хезмәт күрсәтүләр буенча әлеге тәртип (алга таба – Тәртип) түбәндәгеләр нигезендә эшләнде:

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы;
- Россия Федерациясе Салым кодексы;
- Россия Федерациясе Граждан кодексы;
- «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге № 2300-1 Россия Федерациясе Законы;
- «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге № 125-ФЗ Федераль закон;
- «Татарстан Республикасында архив эше һәм архивлар турында» 1996 елның 13 июнендәге № 644 Татарстан Республикасы Законы;
- Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивлардагы, музейлардагы һәм китапханәләрдәге, Россия Федерациясе Фәннәр академиясе оешмаларындагы башка архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм алардан файдалану буенча Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының 2007 елның 18 гыйнварындагы № 19 боерыгы белән расланган кагыйдәләре.

1.2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

Учреждение – үзенә карата гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты башкаручы дәүләт учреждениесе;

Кулланучы – түләүле хезмәт күрсәтелүче физик яисә юридик зат.

1.3. Түләүле хезмәтләр халыкның Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны ихтыяҗларын төрле яклап канәгатьләндерүне, хезмәт күрсәтүләрне үстерү һәм камилләштерү өчен финанс чараларын җәлеп итүне, матди-техник базаны ныгытуны оештыру максатларында күрсәтелә.

1.4. Түләүле хезмәтләр күрсәтү Учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлегенең бер өлеше була.

1.5. Әлеге Тәртип түбәндәгеләрне билгели:

- түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен;
- түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяне (тарифны) билгеләү тәртибен;
- түләүле хезмәтләр күрсәтүдән килгән керемнәрне планлаштыру һәм алардан файдалану тәртибен;
- түләүле хезмәтләр күрсәтүләрне исәпкә алуны оештыруны һәм түләүле хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген тикшереп торуны.

## 2. Түләүле хезмәт күрсәтүләр төрләре

2.1. Учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр төрләре исемлеге Учреждение Уставында карала.

2.2. Учреждение Уставта каралмаган хезмәтләрне күрсәтергә хокуклы түгел.

## 3. Хезмәт күрсәтүләрне оештыру

3.1. Түләүле хезмәтләр учреждениеләр тарафыннан шартнамә нигезендә яисә хезмәт күрсәтү өчен түләне раслаучы бүтән документ нигезендә күрсәтелә, аларда түләү суммалары күрсәтелергә тиеш.

3.2. Шартнамә яисә 3.1 пунктта күрсәтелгән бүтән документ формасы законнар нигезендә билгеләнә.

3.3. Түләүле хезмәтләр күрсәткәндә әлеге учреждениенең билгеләнгән эш режимы сакланып кала, бу чакта түләүсез нигездә күрсәтелүче хезмәтләр кыскармаска, һәм аларның сыйфаты начараймаска тиеш, шулай ук төп устав эшчәнлеге урынына яисә аңа зыянга түләүле хезмәтләр күрсәтү рөхсәт ителми.

3.4. Учреждение хезмәтләр күрсәтү вакытын ихтирамга лаеклы сәбәпләр аркасында (үзгәртеп булмаслык хәлләр нәтиҗәсендә) күчерергә хокуклы, бу чакта ул хезмәт күрсәтү көненә бер календарь көн кала Кулланучыга хәбәр итәргә тиеш. Хәбәр итү рәвеше хезмәт күрсәтүләр кагыйдәләре нигезендә билгеләнә. Кулланучы хезмәт күрсәтүне күчерү белән риза булмаган очракта, Кулланучыга элек түләнгән, әмма күрсәтелмәгән хезмәт күрсәтү хакы кире кайтарыла.

3.5. Учреждениеләр түләүле хезмәт күрсәтүләр турында түбәндәге күргәзмә мәгълүмат белән кулланучыларны тәэмин итәргә тиеш:
- Учреждениенең эш режимы;
- түләүле хезмәт күрсәтүләр графигы;
- түләүле хезмәт күрсәтүләр төрләре, аларның хакын күрсәткән килеш;
- түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм күрсәтелү шартлары;
- гражданнарның аерым категорияләре өчен ташламалар турында мәгълүмат.

3.6. Күрсәтелгән түләүле хезмәтләр өчен кулланучылар белән исәп-хисапларны өзү акчалата булмаган рәвештә акчаларны билгеләнгән тәртиптә учреждениенең шәхси счетына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.7. Учреждениеләр түләүле хезмәтләрне мөстәкыйль рәвештә һәм (яисә) Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамә нигезендә өченче затларны җәлеп итү (уртак катнашу) юлы белән гамәлгә ашырырга мөмкин.

3.8. Учреждение тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтелгәндә кулланучыларның аерым категорияләре өчен ташламалар бирелергә мөмкин. Ташламалар Учреждение җитәкчесе боерыгы белән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

3.9. Түләүле хезмәтләрне ташламалы шартларда күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүмат Учреждение бинасының шунда килүчеләр була торган зоналарында урнаштырыла.

## 4. Түләүле хезмәт күрсәтү бәясен (тарифын) билгеләү тәртибе

4.1. Түләүле хезмәт күрсәтү бәясен (тарифын) исәпләп чыгару һәм раслау «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләренең төп эшчәнлек төрләренә карый торган хезмәт күрсәтүләр (эшләр башкару) өчен, гражданнар һәм юридик затлар өчен түләү билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2010 № 1170 карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Учреждение Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма органы белән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге белән килештерү нигезендә түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне раслый.

## 5. Түләүле хезмәт күрсәтүдән килгән керемнәрне планлаштыру һәм куллану тәртибе

5.1. Түләүле хезмәт күрсәтүдән килгән керемнәрне планлаштыру һәр конкрет түләүле хезмәт күрсәтү буенча Учреждение эшчәнлегенең санлы күрсәткечләре нигезендә, шулай ук Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Учреждениеләр ел саен киләчәк финанс елына бюджет классификациясе киселешендә норматив хокукый актлар белән билгеләнгән срокларда түләүле хезмәт күрсәтүләрдән килгән керемнәрнең фаразын төзи һәм аны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына тапшыра.

5.3. Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән килгән керемнәрнең кимендә 50%ы, хезмәт өчен түләүгә өстәлмәләрне һәм Учреждение хезмәткәрләрен кызыксындыру рәвешендәге түләүләрне дә кертеп, хезмәт өчен түләүгә җибәрелә.

## 6. Түләүле хезмәт күрсәтүләрне исәпкә алуны оештыру

һәм түләүле хезмәт күрсәтүләр эшчәнлеген тикшереп тору

6.1. Учреждениеләр түләүле хезмәт күрсәтүләрне бухгалтер, салым һәм статистик исәпкә алуны билгеләнгән тәртиптә алып баралар.

6.2. Учреждениеләрнең түләүле хезмәт күрсәтүләр эшчәнлеген тикшереп тору Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм законнар нигезендә учреждениеләр эшчәнлеген тикшереп тору һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы бүтән органнар гамәлгә ашыра.

6.3. Учреждениеләрнең түләүле хезмәт күрсәтүләр эшчәнлеген оештыру һәм түләүле хезмәт күрсәтүләрдән килгән керемнәрне исәпкә алу өчен Учреждение житәкчесе җаваплы була.